2024 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авылы җирлеге Колшәрип авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

4 декабрь 2023 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлегенең Колшәрип авылында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлегенең Колшәрип авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: урам яктырту челтәрләрен, су белән тәэмин итү системасын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык коммуникацияләрен ремонтлау, су чыганакларыннан су алу, торак пункт чикләрендә гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын ремонтлау, смета төзү, җирлеккә техник күзәтү ясау, җирлек милкенә күзәтүне рәсмиләштерү.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Колшәрип авылы, Тукай урамы, 50 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Колшәрип авыл җирлеге башлыгы А.Ф. Кәшәфетдинов